Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы Тәмте авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2019 ел, 9 декабре Зномерлы

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы Тәмте авыл җирлегенең Тукай авылында булып узган халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына нигезләнеп, 2019 елның 9 декабрендә булып узган халык җыены нәтиҗәсеннән түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде:
"2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлегенең Тукай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, (көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш) , 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

**- кышкы-җәйге чорда авыл эчендәге һәм урамара юлларны тәртиптә тоту;**
**- урам утларын карап тоту."**

Халык җыены нәтиҗәләре түбәндәгеләр:

Сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 18 кеше кертелгән, җыенда 12 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 12 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге составына керүче Тукай авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.
2. Халык җыенына куелган : «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге составына керүче Тукай авылында

яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (льготалы кешеләрдән һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш)  300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерү белән килешәсезме?:

**- кышкы-җәйге чорда бистәләр эчендәге һәм урамара юлларны тәртиптә тоту;**
**- урам утларын карап тоту.”** соравы буенча карарны кабул ителгән дип санарга.
3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Теньки авылы  2 нче Октябрь ур.,  50 йорт
(мәдәният йорты дивары)
- ТР, Кама Тамагы районы, Теньки авылы  2 нче Октябрь ур.,  65 йорт
(администрация дивары).

Шулай ук, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

ТР Кама Тамагы муниципаль районы
Тәмте авыл жирлеге башлыгы И.А.Зиновьев